ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.12.2024 № 1525

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 17 октябрендәге 985 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 17 октябрендәге 985 номерлы белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 5 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында. (nurlat.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы»муниципаль казна учреждениесе рәисенә йөкләргә..

Җитәкче Ә.К. Габдуллин